| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» август 2024 г. № 113

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (baltasi.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының Авыл хуҗалыгы, җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре , әйләнә-тирә мохитне саклау, чисталык, төзекләндерү, яшелләндерү буенча комиссиясенә йөкләргә.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин